**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УРАЗАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**423750, Уразай авылы,**
**Центральная урамы, 4 нче йорт**
**тел.3-44-62**
e-mail : Uraz.Akt@tatar.ru

**УРАЗАЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423750, дер.Уразаево,**
**ул.Центральная,**
**дом 4., тел. 3-44-62.**
e-mail : Uraz.Akt@tatar.ru

**КАРАР** — **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

15 гыйнвар 2022 ел — №3

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Уразай авыл җирлеге каршындагы Хатын-кызлар советының эш планын раслау турында**

Хатын-кызлар һәм балалар мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру, Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең иҗтимагый-сәяси, икътисадый, социаль һәм мәдәни тормышында хатын-кызларның ролен күтәрү максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге Закон нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Уразай авыл җирлеге каршындагы Хатын-кызлар советының кушымтада бирелгән эш планын расларга.
2. Актаныш муниципаль районының Уразай авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие һәм учреждениеләр җитәкчеләренә Хатын-кызлар советы эшчәнлегенә ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының Уразай авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Уразай авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфасын башкаручы — Д.Д.Миргалимова

Уразай авыл җирлегене
башкарма комитеты карарына
15.01.2022 ел, №3
1 нче кушымта

2022 елга Уразай авыл җирлеге Хатын-кызлар советының эш планы

| № | Чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Җирлек Хатын-кызлар советының бурычлары турында утырыш үткәрү һәм 2022 елга эш планын раслау. | квартал саен | Совет рәисе,<br>совет әгъзалары |
| 2. | Үткәрүдә катнашу:<br>- республика көне;<br>- Халыкара хатын-кызлар көне;<br>- гаилә көне;<br>- Балаларны яклау көне;<br>- өлкәннәр көне;<br>- авыл җирлекләре арасында спартакиадалар;<br>- әниләр көне;<br>- 1941-1945 елларда Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 76 еллыгын бәйрәм итү;<br>-милли Сабантуй бәйрәме;<br>«Ягез әле, кызлар, әниләр, әбиләр!»;<br>- Үзешчән сәнгать смотры | ел дәвамында | Совет рәисе,<br>совет әгъзалары |
| 3. | «Уразай авыл җирлегенең Хатын-кызлар советы эшчәнлеге» папкасын һәм стендын бизәү | ел дәвамында | Совет рәисе,<br>совет әгъзалары |
| 4. | Хатын-кызлар советы эшчәнлегенә анализ ясарга, нәтиҗәләр буенча аны камилләштерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр эшләргә | ел дәвамында | Совет рәисе,<br>совет әгъзалары |
| 5. | Участок уполномоченныйлары һәм ПДН инспекторлары белән берлектә, социаль имин булмауның сәбәпләрен ачыклау максатыннан, яшәү урыны буенча бару:<br>- исерткеч эчемлекләр белән кирәгеннән артык мавыгучы гаиләләр;<br>- балигъ булмаган хокук бозучылар; | ел дәвамында | Совет рәисе,<br>совет әгъзалары |
| 6. | Җәмгыятьнең аерым игътибарына мохтаҗ булган хатын-кызларның исәбен алып барырга (күп балалы, ялгыз аналар, ялгыз өлкән яшьтәгеләр, эчүчеләр һ. б.) | ел дәвамында | Совет рәисе,<br>совет әгъзалары |
| 7. | Хатын-кызларга ярдәмгә мәгълүмати-белешмә, методик материаллар әзерләү | ел дәвамында | Совет рәисе, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | совет әгъзалары |
| 8. | Беренче сыйныфка баручы балаларның әниләре белән «Беренче сыйныф укучысының адаптациясендә гаиләнең роле» темасына очрашу оештыру | август | җирлек мәктәбе укытучылары |
| 9. | Сәламәтлек саклау органнары белән берлектә имин булмауның башлангыч стадиясендә гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны ачыклау. Әлеге гражданнар белән индивидуаль-профилактик эш алып бару | ел дәвамында | Совет рәисе,<br>совет әгъзалары |
| 10. | Эчке эшләр бүлеге һәм җирлек җәмәгатьчелеге советы белән үзара хезмәттәшлектә законсыз алкоголь сату урыннарын ачыклау һәм нейтральләштерү, ялган алкоголь продукциясенә рейдлар үткәрү | ел дәвамында | Совет рәисе,<br>совет әгъзалары |
| 11. | Авыл җирлегенең җәмәгатьчелек советы белән берлектә яшьләрнең күпләп җыела торган урыннарында эчүне, наркоманияне һәм тәмәке тартуны кисәтү һәм башка хокук бозуларны булдырмау максатыннан рейдлар үткәрү. | ел дәвамында | Совет рәисе,<br>совет әгъзалары |
| 12. | Яшьләр һәм башка затлар тарафыннан хокук бозуларны булдырмау максатында массакүләм чараларда кизү торуларда катнашу. | ел дәвамында | Совет рәисе,<br>совет әгъзалары |